| ГЛАВА<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.04.2019 г. Агрыз № 28

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Иҗтимагый совет турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору эшен координацияләү комиссиясенең 24.09.2018 утырышы беркетмәсенең 4.3 пункты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумының 11.02.2019 утырыш беркетмәсенең 5.1 пункты нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башлыгының 2013 елның 27 декабреннән 128 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 пунктын түбәндәге абзацлар белән тулыландырырга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруда катнашу;
- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыруда катнашучы Җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары, оешмалар, шул исәптән иҗтимагый берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек;
- җәмгыятьтә коррупциягә карата түземсез мөнәсәбәт формалаштыру буенча эшне гамәлгә ашыру;
- коррупциягә каршы көрәш чараларында җәмәгать контролен гамәлгә ашыру.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе Р.А. Закировага йөкләргә.

Совет Агрызского муниципального района Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы
Общий отдел
Гомуми бүлек

**В.В. МАКАРОВ**